## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**18.10.2024 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Шаршады авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Шаршады торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында карар

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның «18 » октябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплап җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Шаршады авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Шаршады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Шаршады авылындагы Лесоводлар урамы өчен вак таш сатып алу һәм салу);
- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, мотопомпа сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү);
- Урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү;
- Шаршады авылы урамнарын кардан чистарту.
- Халыкны су белән тәэмин итү (су белән тәэмин итү өчен тирән насосларны ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү, сатып алу).
-Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (2 (ике) данә күләмендә триммер сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 170 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 110 кеше, бу 65 % тәшкил итә

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 110 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Шаршады авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Шаршады торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Шаршады авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Шаршады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, студентлардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булучы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (мобилизацияләнгән, иреклеләр контракты буенча хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларын (ата-аналарын, ирләрен хатыннарын, балигъ булган балаларны) түләүдән азат итеп, 2025 елда үзара салым чараларын 500 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Шаршады авылындагы Лесоводлар урамы өчен вак таш сатып алу һәм салу);

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, мотопомпа сатып алу, хезмәт шартнамәсе буенча янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү);

- Урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәт шартнамәсе буенча электрикка түләү;

- Шаршады авылы урамнарын кардан чистарту.

- Халыкны су белән тәэмин итү (су белән тәэмин итү өчен тирән насосларны ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү, сатып алу).

-Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (2 (ике) данә күләмендә триммер сатып алу).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы С.Л. Залётов